

Урнашылган гадәт буенча, Кадошкино районы Большиеполяны гомуми топ белем бирv мәктәбе укучылары, житәкчеләре белән бергә, урманга сәяхәткә чыгалар.
Жәйге кон һәм кәефләр кыяшлы иде бу вакыт барчасында. Урман безнен дустыбыз һәм урман матурлыгы кешене һәрвакыт vзенә тартып тора. Матур агачлары, кошларнын оздереп сайравы кvнелләрне тибрәтә, тынлык ниндидер сихри донья кvк тыела. Урманнын саф һавасы сукмаклары буйлап йортми, ә очыртып алып бара, нәкъ йозәсен тосле. Шул язгы урманда, сәяхәткә килгән балалар, рәхәтләнеп торле уеннардан уйнадылар; сихри матурлыкка сокланып карап тордылар.       Юлда очраган яфраклар, тосле ташлар, зирек алкалары, чыршы кvркәләре кул эшләренә бик тә ярап тора; сәяхәтчеләр аларны капчыкларына тутырып бардылар. Шулай башлангыч сыйныфлылар яна уку елына кvп материал тупладылар. Ә олкән сыйныф укучылары «Туган як чишмәләрен чистартыйк!» дигән экологик акция vткәрергә дә олгерделәр. Элекке умарта утарында бик матур бер чишмә бар. Аны



«пчелник» чишмәсе дип йортә авыл халкы һәм һәрвакыт тәртиптә тота. Заманында пионер лагере дә шунда эшләп килде һәм жәйге лагерьдә ял иткән укучыларга шул чишмә суында поварлар ашарга да пешерә иделәр. Урманга килгән кешеләр дә шул «пчелник» чишмәсенә туктап хәл жыялар, суын тәмләп эчәләр, савытларга тутырып алып та кайталар. Урман чишмәсенен суы тәмле дә, файдалы да.
Һәр елны, шул исәптән быел да, биология укытучысы Рәстәм Шакир улы Кильдеев житәкчелегендә, укучылар чишмәнен тирә-ягын чистартып алдылар. Ә чишмәнен яна бурасын, сукмак баскычларын, тоткасы белән бергә, vткән ел Саранск шәһәрендә

яшәгән А.В.Куликов спонсорлыгы ярдәмендә химия-биология укытучысы Рәстәм Шакир улы Кильдеев, родителебез Рамиль Равил улы Кильдеев һәм башка ата-аналар эшләгән иделәр. Рәхмәтле кешеләр доньяда байтак. Иса авылы халкы чишмәләрен саклый. Шулай, Апсятар тавы итәгендә урнашкан «пирләткә» чишмәсенен бурасын һәм тvбәсен, vз акчаларына һәм vз кул кочләре белән Артур Наиль улы Мангутов һәм Наиль Равил улы Капкаев ясадылар. Кvрше Насаканпотьма авылы чишмәсен дә тәртиптә тоталар. Сәяхәттәге vткәргән сәгатьләр минутларга тин vтте дә китте. Кайтасы юлда Исса елгасы буенда да ял иттек. Тулы сулы елгабызны да искә алдык. Хәзер елгабызнын суы саекты, тирә-ягын тал агачлары каплады. Борынгылар әйтмешли, тулы елган булган чакта, унышын да мул була. Игеннәрнен уныш бирvләренен рәте китvендә экологиянен роле зур. Шуна да без кvз карасы тик саклыйбыз табигатебезне.

**Светлана Кильдеева**